| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 8 июне** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1530** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 06 февралендәге 260 номерлы “Зеленодольск шәһәре, Крылов урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында” карары үз көчен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 февралендәге 359 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан ТР Зеленодольск шәһәре, Крылов урамы, 5 йорт адресы чыгу уңаеннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 06 февралендәге 260 номерлы «Зеленодольск шәһәре, Крылов урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:

-күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУна;

- торак биналар милекчеләренә җибәрергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А. Н. Коршуновка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълумати сайтында (http://zelenodosk.tatarstan.ru) Интернет

челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин